**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 9 июнь

№ 383

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 21 июль, 521 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2014 ел, 6 декабрь, 950 нче; 2015 ел, 6 май, 329 нчы; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2015 ел, 1 декабрь, 910 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Программаның бурычлары» юлына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы халкының уңай яшәү шартларын тудыру өчен социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү»;

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлында:

икенче абзацта «2015» саннарын «2016» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«8. «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасы

кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм аларны капиталь ремонтлау»;

«Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td>
<td>Программаны финанслау күләме 2014 – 2020 елларда 5 528 930,9 мең сум*, шул исәптән:<br>билгеләнгән тәртиптә бирелә торган федераль бюджет акчасы – 429 770,5 мең сум;<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 3 458 766,4 мең сум;<br>җирле бюджетларда күздә тотылган акча – 1 640 394,0 мең сум;<br>шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Акча чыганагы</th><th rowspan="2">Барлыгы</th><th colspan="7">Еллар буенча чыгымнар күләмнәре</th></tr>
<tr><th>2014 ел</th><th>2015 ел</th><th>2016 ел</th><th>2017 ел</th><th>2018 ел</th><th>2019 ел</th><th>2020 ел</th></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>429 770,5</td><td>109 110,2</td><td>72 825,8</td><td>49 566,9</td><td>49 566,9</td><td>49 566,9</td><td>49 566,9</td><td>49 566,9</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы бюджеты</td><td>3 458 766,4</td><td>1 216 164,0</td><td>697 012,1</td><td>329 987,5</td><td>288 768,0</td><td>298 987,2</td><td>309 150,1</td><td>318 697,5</td></tr>
<tr><td>Җирле бюджетлар</td><td>1 640 394,0</td><td>307 600,0</td><td>290 707,0</td><td>108 187,0</td><td>233 475,0</td><td>233 475,0</td><td>233 475,0</td><td>233 475,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы*</td><td>5 528 930,9</td><td>1 632 874,2</td><td>1 060 544,9</td><td>487 741,4</td><td>571 809,9</td><td>582 029,1</td><td>592 192,0</td><td>601 739,4</td></tr>
</table>
* Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

«Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын тулы күләмдә тормышка ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>2014 елга:<br>җирлекләрне яшелләндерү дәрәҗәсен 27 процентка кадәр арттырырга;<br>2015 елга:<br>атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәпләре булган Татарстан Республикасының эре шәһәрләре санын 5 кә кадәр арттырга;<br>туфраклар сыйфатының эшләнгән һәм гамәлгә кертелгән төбәк нормативлары санын 30 берәмлеккә кадәр арттырырга;<br>суның тискәре йогынтысына дучар булган территорияләрдә |

| | |
|---|---|
| | яшәүче, әлеге йогынтыдан саклауны арттыру буенча чаралар үткәрү нәтиҗәсендә сакланылган халык өлешен әлеге территорияләрдә яшәүче халыкның гомуми санында 57,2 процентка кадәр арттырырга;<br>инженерлык саклавының һәм ярны ныгытуның төзекләндерелгән яңа корылмалары озынлыгын 12,45 километрга кадәр арттырырга;<br>куркыныч һәм канәгатьләндермәслек куркынычсызлык дәрәҗәсендә булган, куркынычсыз техник хәлгә китерелгән гидротехника корылмалары санын 20 берәмлеккә арттырырга;<br>куркынычсыз техник хәлгә китерелгән гидротехника корылмалары өлешен куркыныч һәм канәгатьләндермәслек куркынычсызлык дәрәҗәсе булган гидротехника корылмаларының гомуми санында 26 процентка кадәр арттырырга;<br>су объектларын тергезү һәм экологик тернәкләндерү чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә экологик яшәү шартлары яхшыртылачак халык санын 15,643 мең кешегә арттырырга;<br>2016 елга:<br>әйләнә-тирә мохит торышын күзәтү территориаль системасы булган Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) санын 33 кә кадәр арттырырга;<br>җитештерү һәм куллану процессында барлыкка килгән калдыкларның гомуми күләмендә файдаланылган, зарарсызландырылган калдыклар өлешен 36 процентка кадәр арттырырга;<br>2020 елга:<br>стационар чыганаклардан чыга торган пычраткыч матдәләрнең гомуми санында тотылган һәм зарарсызландырылган атмосфера һавасын пычраткыч матдәләр өлешен 60,1 процентка кадәр арттырырга;<br>тикшертелгән автомобильләрнең гомуми санында эшләп чыгарылган газларында пычраткыч матдәләр артык күп булган автотранспорт чаралары өлешен 13 процентка кадәр киметергә;<br>пычранган (чистартылмаган) агынты суларның өлешен чыгарылган суның гомуми күләмендә 11,65 процентка кадәр киметергә;<br>яңадан культивацияләнә торган җирләр өлешен 45 процентка кадәр арттырырга;<br>табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә билгеле булган бозулар арасыннан бетерелгән бозулар өлешен 95,5 процентка кадәр арттырырга;<br>әйләнә-тирә мохитнең торышы, аның пычрануы белән бәйле тискәре күренешләр (тенденцияләр) турындагы фаразларның һәм кисәтүләрнең раслану процентын 93-95 процентка кадәр арттырырга; |

| | |
|---|---|
| | геология, гидрогеология һәм геоэкология тикшеренүләренең яңа мәгълүматлары булган Татарстан Республикасы территориясе мәйданын 24 процентка кадәр зурайтырга;<br>куркыныч экзоген геологик процесслар (алга таба – КЭГП) мониторингы булган Татарстан Республикасы муниципаль районнары санын КЭГП тискәре йогынтысына дучар булган Татарстан Республикасы муниципаль районнары санына карата мөнәсәбәтен 36 процентка кадәр арттырырга;<br>4 перспективалы гомумтаралган файдалы казылмалар участогын ел саен билгеләүне тәэмин итәргә;<br>геологик мохит мониторингы булган территория мәйданын Татарстан Республикасы территориясенең гомуми мәйданында 46 процентка кадәр арттырырга;<br>җир асты суларының расланган эксплуатация запаслары күләмен аларның фаразланган эксплуатация ресурсларында 40,9 процентка кадәр арттырырга;<br>суны исәпләү системалары белән җиһазландырылган су алу корылмалары өлешен су алу корылмаларының гомуми санында 96 процентка кадәр арттырырга;<br>билгеләнгән тәртиптә бирелгән куллану хокуклары нигезендә су объектларыннан файдалануны гамәлгә ашыра торган суны кулланучылар өлешен судан файдалануны гамәлгә ашырулары су объектларыннан файдалану хокукларын сатып алуны күздә тоткан кулланучыларның гомуми санында 99 процентка кадәр арттырырга;<br>барлык дәрәҗәдәге махсус саклана торган табигать территорияләре (алга таба – МСТТ) урнашкан Татарстан Республикасы мәйданы өлешен 2,6 процентка кадәр арттырырга;<br>Татарстан Республикасының МСТТдә билгеле булган һәм бетерелгән бозулар санын 670 берәмлеккә кадәр арттырырга;<br>аучылык ресурслары һәм аларның яшәү мохите дәүләт мониторингы кысаларында, аучылык ресурслары санын исәпкә алу башкарылган аучылык ресурслары төрләренең өлешен Татарстан Республикасы территориясендә булган аучылык ресурслары төрләренең гомуми санында 32 процентка кадәр арттырырга;<br>федераль дәүләт аучылык күзәтчелеге өлкәсендә билгеле булган, җаваплылыкка тартылу турында карарлар чыгарылган бозулар өлешен билгеле булган бозу фактларының гомуми санында 89 процентка кадәр арттырырга»; |

II бүлектә:

«Программаның максаты һәм бурычлары» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«8. «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм аларны капиталь ремонтлау.»;

«Ярдәмче программалар исемлеге» бүлекчәсендә:

өченче абзацта «2020» саннарын «2016» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«8. «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм аларны капиталь ремонтлау.»;

«2014 – 2015 елларга Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары әйләнеше өлкәсендә дәүләт идарәсе» ярдәмче программасы чаралары» бүлекчәсендә:

исемдәге «2015» саннарын «2016» саннарына алмаштырырга;

беренче абзацта «2020» саннарын «2016» саннарына алмаштырырга;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге хезмәтләренең эшчәнлеген яраштыру» ярдәмче программасы чаралары» бүлекчәсеннән соң түбәндәге эчтәлекле «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм аларны капиталь ремонтлау» ярдәмче программасы чаралары» бүлекчәсен өстәргә:

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм аларны капиталь ремонтлау» ярдәмче программасы чаралары

Татарстан Республикасының иҗтимагый инфраструктурасын үстерү максатларында, «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм аларны капиталь ремонтлау» ярдәмче программасында Татарстан Республикасының су объектларында ярны ныгыту һәм су төбен тирәнәйтү эшләре үткәрү каралган.»;

«Программаны тормышка ашыру күрсәткечләре (индикаторлары) һәм вакытлары» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны тормышка ашыру күрсәткечләре (индикаторлары) һәм вакытлары

Программаны төп тормышка ашыру күрсәткечләренә (индикаторларына) түбәндәгеләр керә:

әйләнә-тирә мохит торышын күзәтү территориаль системасы булган муниципаль районнар (шәһәр округлары) саны, берәмлек;

әйләнә-тирә мохитнең торышы, пычрануы белән бәйле тискәре күренешләр (тенденцияләр) турындагы фаразлар һәм кисәтүләр раслану өлеше, процент;

атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәпләре булган Татарстан Республикасының эре шәһәрләре саны, берәмлек;

Татарстан Республикасында парник газлары чыгарылуның мәгълүматлар базасы, берәмлек;

туфраклар сыйфатының эшләнгән һәм гамәлгә кертелгән төбәк нормативлары саны, берәмлек;

җирлекләрне яшелләндерү дәрәҗәсе, процент;

әйләнә-тирә мохит торышы турындагы дөрес мәгълүматтан файдалана алу мөмкинлеге булган Татарстан Республикасы халкы өлеше, процент;

басма, электрон массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган һәм шәһәр, республика каналларында трансляцияләнә торган экология тематикасына максатчан мәгълүмати материаллар саны, берәмлек;

республикада яшәүчеләрнең гомуми саныннан табигатьне саклау, экология-агарту чараларында катнашучы халык өлеше, процент;

җитештерү һәм куллану процессында барлыкка килгән калдыкларның гомуми күләмендә файдаланылган, зарарсызландырылган калдыклар өлеше, процент;

Татарстан Республикасының каты көнкүреш калдыклары полигоннарында урнаштырыла торган калдыкларның гомуми күләменнән чыгарылган икенчел ресурслар өлеше, процент;

каты көнкүреш калдыкларының бетерелгән санкцияләнмәгән чүплекләре, процент;

биологик калдыкларны җыю һәм чыгару өчен сатып алынган контейнерлар саны, данә;

әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны дәүләт җайга салуына кагылышлы экологик нормалаштыру өлкәсендә чыга торган документлар саны, данә;

Татарстан Республикасы территориясендә Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары акваториясендә урнашкан, тикшерелгән баткан йөзү чаралары саны, берәмлек;

КЭГП мониторингы булган Татарстан Республикасы муниципаль районнары санының КЭГП тискәре йогынтысына дучар булган Татарстан Республикасы муниципаль районнары санына карата мөнәсәбәте, процент;

Татарстан Республикасы территориясенең гомуми мәйданына карата геология, гидрогеология һәм геоэкология тикшеренүләренең яңа мәгълүматлары булган территория мәйданы чагыштырмасы, процент;

1 мең нөсхә тиражлы «Георесурслар» журналы чыгарылышлары саны, чыгарылышлар;

билгеләнгән перспективалы гомумтаралган файдалы казылмалар участогы саны, участоклар;

Татарстан Республикасы территориясенең гомуми мәйданына карата геологик мохит мониторингы булган территория мәйданы чагыштырмасы, процент;

җир асты суларының расланган эксплуатация запаслары һәм аларның фаразланган эксплуатация ресурслары чагыштырмасы, процент;

су алу корылмаларының гомуми санында суны исәпләү системалары белән җиһазландырылган су алу корылмалары өлеше, процент;

судан файдалануны гамәлгә ашырулары су объектларыннан файдалану хокукларын сатып алуны күздә тоткан кулланучыларның гомуми санында билгеләнгән тәртиптә бирелгән куллану хокуклары нигезендә су объектларыннан файдалануны гамәлгә ашыра торган суны кулланучылар өлеше, процент;

федераль милектә булган су объектарыннан файдалану өчен түләү суммаларының расланган план мәгънәләренә карата су объектларыннан файдалану өчен түләү суммаларының Россия Федерациясе бюджет системасына фактта кертелү күләме чагыштырмасы, процент;

суның тискәре йогынтысына дучар булган территорияләрдә яшәүче халыкның гомуми санында әлеге территорияләрдә яшәүче, суларның тискәре йогынтысыннан саклауны арттыру буенча чаралар үткәрү нәтиҗәсендә сакланылган халык өлеше, процент;

инженерлык саклавының һәм ярны ныгытуның яңа һәм төзекләндерелгән корылмалары озынлыгы, километр;

куркыныч һәм канәгатьләндермәслек куркынычсызлык дәрәҗәсе булган гидротехника корылмаларының гомуми санында куркынычсыз техник хәлгә китерелгән куркыныч һәм канәгатьләндермәслек куркынычсызлык дәрәҗәсе булган гидротехника корылмалары өлеше, процент;

куркыныч һәм канәгатьләндермәслек куркынычсызлык дәрәҗәсендә булган, куркынычсыз техник хәлгә китерелгән гидротехника корылмалары саны, берәмлек;

су объектларын тергезү һәм экологик тернәкләндерү чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә экологик яшәү шартлары яхшыртылачак халык саны, кеше;

су объектларын тергезү һәм экологик тернәкләндерү чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә су төбендәге утырмаларның уентысы күләме, мең куб.метр;

су объектларын тергезү һәм экологик тернәкләндерү эшләре озынлыгы, километр;

су объектларын тергезү һәм экологик тернәкләндерү эшләре мәйданы, кв.километр;

Түбән Кама муниципаль районы торак пунктларында төзелгән биологик чистарту корылмалары саны;

Татарстан Республикасының гомуми мәйданында барлык дәрәҗәдәге МСТТ урнашкан Татарстан Республикасы мәйданы өлеше, процент;

төбәк һәм җирле әһәмияттәге МСТТ урнашкан Татарстан Республикасы мәйданы өлеше, процент;

Татарстан Республикасының МСТТдә билгеле булган һәм бетерелгән бозулар саны, берәмлек;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән төрләр саны, берәмлек;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән, тагын да «түбән» сирәклек категориясенә күчерелгән төрләр саны, берәмлек;

Татарстан Республикасының Кызыл китабыннан чыгарылган төрләр саны, берәмлек;

МСТТ мәсьәләләре буенча басмалар саны, данә;

МСТТ мәсьәләләре буенча лекцияләр һәм башка гавами чаралар узган укучылар саны, кеше;

Татарстан Республикасы территориясендә булган аучылык ресурслары төрләренең гомуми санында аучылык ресурслары саны мониторингы алып барылган аучылык ресурслары төрләренең өлеше, процент;

билгеле булган бозу фактларының гомуми санында федераль дәүләт аучылык күзәтчелеге өлкәсендә билгеле булган, җаваплылыкка тартылу турында карарлар чыгарылган бозулар өлеше, процент;

аучылык биләмәләренең гомуми мәйданында хуҗалык эчендә аучылык чаралары үткәрелгән аучылык биләмәләре мәйданы өлеше, процент;

ташлап калдырылган тоту (аулау) коралларыннан чистартылган акватория мәйданы, кв.километр;

хуҗалык яки башка эшчәнлекне планлаштырганда әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләрне үтәүне тәэмин итүдә чыга торган документлар саны, берәмлек;

хуҗалык яки башка эшчәнлекне планлаштырганда әйләнә-тирә мохитне саклау, территориаль планлаштыру һәм дәүләт экология экспертизасы өлкәсендәге теркәлгән мөрәҗәгатьләр саны һәм әзерләнгән килештерүләр һәм үткәрелгән дәүләт экология экспертизалары саны чагыштырмасы, процент;

стационар чыганаклардан чыккан пычраткыч матдәләрнең гомуми күләмендә тотылган һәм зарарсызландырылган атмосфера һавасын пычраткыч матдәләр өлеше, процент;

тикшертелгән автомобильләрнең гомуми санында эшләп чыгарылган газларында пычраткыч матдәләр артык күп булган автотранспорт чаралары өлеше, процент;

чыгарылган суның гомуми күләмендә пычранган (чистартылмаган) агынты сулары өлеше, процент;

яңадан культивацияләнә торган җирләр өлеше, процент;

табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә билгеле булган бозулар арасыннан бетерелгән бозулар өлеше, процент;

тышкы мохитнең (су, һава һәм туфрак) сайлап алынган пробалары саны, данә;

тышкы мохитнең (су, һава һәм туфрак) сайлап алынган пробаларына үткәрелгән лаборатория анализлары саны, данә;

геология тикшеренүләре эшләре нәтиҗәләре турында хисаплар саны һәм үткәрелгән дәүләт экспертизалары саны чагыштырмасы, процент;

нефть скважиналарын эксплуатация бораулавы факттагы күләменең планлаштырылганына карата чагыштырмасы, процент;

нефть скважиналарын эзләү-тикшеренү бораулавы факттагы күләменең планлаштырылганына карата чагыштырмасы, процент;

мөрәҗәгатьләрнең гомуми санына карата геологик мәгълүмат бирүгә канәгатьләндерелгән заявкалар саны чагыштармасы, процент;

Татарстан Республикасының гомумтаралган файдалы казылмалары запасларының еллык расланган балансы (ел саен 2020 елга кадәр);

геологик өйрәнү, тикшерену һәм файдалы казылмалар чыгару максаты белән җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы алуга карап тикшерелгән гаризалар санына карата бирелгән лицензияләр саны чагыштырмасы, процент;

расланган план мәгънәләренә карата лицензиядә искәртелгән билгеле вакыйгалар килеп чыкканда, Россия Федерациясе территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар булган җир асты байлыклары участоклары яки җирле әһәмияттәге участоклар буенча җир асты байлыкларыннан файдаланганда, җир асты байлыкларыннан файдалану өчен бер тапкыр бирелә торган түләүләрнең Татарстан Республикасы бюджетына фактта кертелү күләме чагыштырмасы, процент;

аларны күрсәтү буенча административ регламентлар расланган әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге дәүләт хезмәтләренең һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә контроль (күзәтчелек) буенча дәүләт вазыйфаларының Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан күрсәтелә торган әлеге дәүләт хезмәтләренең (дәүләт вазыйфаларының) гомуми күләмендә өлеше, процент;

йөкләмәләрнең гомуми күләмендә Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан билгеләнгән контроль вакытларында башкарылган Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары йөкләмәләре өлеше, процент;

Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Президенты указларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларында һәм боерыкларында бирелгән, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан башкарылган шәхсиләштерелгән йөкләмәләрнең әлеге норматив актларда бирелгән шәхсиләштерелгән йөкәмәләрнең гомуми күләмендә өлеше, процент;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренең гомуми санында элегрәк язма рәвештә җавап бирелгән сорауларны үз эченә алган, язма рәвештә кабат җибәрелгән гражданнар мөрәҗәгатьләре өлеше, процент;

төзелгән контрактларның гомуми кыйммәтендә сатып алуларның үткәрелмәгән конкурентлы ысуллары нәтиҗәләре буенча төзелгән контрактлар кыйммәте өлеше, процент;

Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен үтәү, процент;

бер кешегә исәпләгәндә әйләнә-тирә мохитне саклауга, табигать ресурсларын торгызуга һәм файдалануга Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты чыгымнары, сум;

Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану өлкәсендә яңадан булдырылган социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары саны, берәмлек;

Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану өлкәсендә ремонтланган социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары саны, берәмлек.

Бурычлар яктылыгында Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары турында җентекле мәгълүмат Программага теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.

Программаны тормышка ашыру вакытлары: 2014 – 2020 еллар.»;

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 5 528 930,9 мең сум* тәшкил итә, шул исәптән:

билгеләнгән тәртиптә бирелә торган федераль бюджет акчасы – 429 770,5 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 3 458 766,4 мең сум;

муниципаль районнар бюджетларында күздә тотылган акча – 1 640 394,0 мең сум.

(мең сум)

| Акча чыганагы | Акча, барлыгы | Еллар буенча чыгымнар күләмнәре | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| Федераль бюджет | 429 770,5 | 109 110,2 | 72 825,8 | 49 566,9 | 49 566,9 | 49 566,9 | 49 566,9 | 49 566,9 |
| Татарстан Респуб-ликасы бюджеты | 3 458 766,4 | 1 216 164,0 | 697 012,1 | 329 987,5 | 288 768,0 | 298 987,2 | 309 150,1 | 318 697,5 |
| Җирле бюджетлар | 1 640 394,0 | 307 600,0 | 290 707,0 | 108 187,0 | 233 475,0 | 233 475,0 | 233 475,0 | 233 475,0 |
| Барлыгы* | 5 528 930,9 | 1 632 874,2 | 1 060 544,9 | 487 741,4 | 571 809,9 | 582 029,1 | 592 192,0 | 601 739,4 |

* Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Ярдәмче программалар, финанслау чыганаклары һәм акча белән баш эш итүчеләр яктылыгында Программаны финанслау күләмнәре турында мәгълүмат Программага теркәлгән 2 нче кушымтада китерелә.»;

Программага 1 – 3 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәләләр);

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохите сыйфатын җайга салу» ярдәмче программасында (алга таба – 1 нче ярдәмче программа):

1 нче ярдәмче программа паспортында:

«Еллар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләме» юлында:

беренче абзацта «299 331,9» саннарын «329 871,8» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «1 111,1» саннарын «31 651,0» саннарына алмаштырырга;

«Еллар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программа максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программа максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 1 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>җирлекләрне яшелләндерү дәрәҗәсен 27 процентка кадәр арттырырга;<br>2015 елга:<br>атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәпләре булган Татарстан Республикасының эре шәһәрләре санын 5 кә кадәр арттырга;<br>туфраклар сыйфатының эшләнгән һәм гамәлгә кертелгән төбәк нормативлары санын 30 берәмлеккә кадәр арттырырга;<br>2016 елга:<br>Татарстан Республикасында парник газлары чыгарылуның мәгълүматлар базасын төзергә;<br>әйләнә-тирә мохит торышын күзәтү территориаль системасы булган Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) санын 33 кә кадәр арттырырга;<br>әйләнә-тирә мохит торышы турындагы дөрес мәгълүматтан файдалана алу мөмкинлеге булган Татарстан Республикасы халкы өлешен 0,15 процентка кадәр арттырырга;<br>республикада яшәүчеләрнең гомуми санынnan табигатьне саклау, экология-агарту чараларында катнашучы халык өлешен 30 процентка кадәр арттырырга;<br>2020 елга:<br>әйләнә-тирә мохитнең торышы, аның пычрануы белән бәйле тискәре күренешләр (тенденцияләр) турындагы фаразларның һәм кисәтүләрнең раслану процентын 93-95 процентка кадәр арттырырга»; |

II бүлектә:

утыз өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әйләнә-тирә мохит торышы турындагы дөрес мәгълүматтан файдалана алу мөмкинлеге булган Татарстан Республикасы халкы өлеше (процентларда);»;

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 1 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 329 871,8 мең сум тәшкил итә.

(мең сум)

| Еллар | Акча, барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|---|
| 2014 | 240 035,3 | 240 035,3 |
| 2015 | 53 741,1 | 53 741,1 |
| 2016 | 31 651,0 | 31 651,0 |
| 2017 | 1 111,1 | 1 111,1 |
| 2018 | 1 111,1 | 1 111,1 |
| 2019 | 1 111,1 | 1 111,1 |
| 2020 | 1 111,1 | 1 111,1 |
| Барлыгы | 329 871,8 | 329 871,8 |

Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

1 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2015 елларга Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары әйләнеше өлкәсендә дәүләт идарәсе» ярдәмче программасында (алга таба – 2 нче ярдәмче программа):

исемдәге «2015» саннарын «2016» саннарына алмаштырырга;

2 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программа исеме» юлында «2020» саннарын «2016» саннарына алмаштырырга;

«2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары» юлында «2020» саннарын «2016» саннарына алмаштырырга;

«Еллар буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлында:

беренче абзацта «293 128,6» саннарын «312 596,7» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:

«2016 елда – 19 468,1 мең сум.»;

«Еллар буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программа максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлында:

өченче абзацта «25» саннарын «95» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «29» саннарын «35» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары акваториясендә урнашкан, баткан 101 йөзү чарасын тикшерергә»;

2 нче ярдәмче программаның II бүлегендә:

унтугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге бурычны хәл итүнең төп күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:»;

түбәндәге эчтәлекле егерменче һәм егерме беренче абзацлар өстәргә:

«каты көнкүреш калдыкларының бетерелгән санкцияләнмәгән чүплекләре, процент;

Татарстан Республикасы территориясендә Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары акваториясендә урнашкан, тикшерелгән баткан йөзү чаралары саны, берәмлек.»;

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 2 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 2 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 312 596,7 мең сум тәшкил итә.

(мең сум)

| Еллар | Акча, барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|---|
| 2014 | 164 187,8 | 164 187,8 |
| 2015 | 128 940,8 | 128 940,8 |
| 2016 | 19 468,1 | 19 468,1 |
| Барлыгы | 312 596,7 | 312 596,7 |

Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

2 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2020 елларга җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе» ярдәмче программасына кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының су хуҗалыгы комплексын үстерү» ярдәмче программасына (алга таба – 4 нче ярдәмче программа):

4 нче ярдәмче программа паспортында:

«4 нче ярдәмче программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«4 нче ярдәмче программаны финанслау күләме</td>
<td>4 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 910 068,7 мең сум тәшкил итә, шул исәптән 603 800,6 мең сум – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, 306 268,1 мең сум – билгеләнгән тәртиптә бирелә торган федераль бюджет акчасы, шул исәптән:
<table>
<tr><th>Еллар</th><th>Акча, барлыгы</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>Федераль бюджет акчасы</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>599 184,9</td><td>508 372,8</td><td>90 812,1</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>153 356,8</td><td>94 927,8</td><td>58 429,0</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>31 905,4</td><td>500,0</td><td>31 405,4</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>31 405,4</td><td>-</td><td>31 405,4</td></tr>
</table>
</td>
</tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2018 | 31 405,4 | - | 31 405,4 |
| 2019 | 31 405,4 | - | 31 405,4 |
| 2020 | 31 405,4 | - | 31 405,4 |
| Барлыгы | 910 068,7 | 603 800,6 | 306 268,1 |

Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;

«Еллар буенча бүлеп, 4 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, 4 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 4 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>2015 елга:<br>суның тискәре йогынтысына дучар булган территорияләрдә яшәүче, әлеге йогынтыдан саклауны арттыру буенча чаралар үткәрү нәтиҗәсендә сакланылган халык өлешен әлеге территорияләрдә яшәүче халыкның гомуми санында 57,2 процентка кадәр арттырырга;<br>инженерлык саклавының һәм ярны ныгытуның төзекләндерелгән яңа корылмалары озынлыгын 12,45 километрга кадәр арттырырга;<br>куркыныч һәм канәгатьләндермәслек куркынычсызлык дәрәҗәсендә булган, куркынычсыз техник хәлгә китерелгән гидротехника корылмалары санын 20 берәмлеккә арттырырга;<br>куркынычсыз техник хәлгә китерелгән гидротехника корылмалары өлешен куркыныч һәм канәгатьләндермәслек куркынычсызлык дәрәҗәсе булган гидротехника корылмаларының гомуми санында 26 процентка кадәр арттырырга;<br>су объектларын тергезү һәм экологик тернәкләндерү чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә экологик яшәү шартлары яхшыртылачак халык санын 15,643 мең кешегә арттырырга;<br>су объектларын тергезү һәм экологик тернәкләндерү чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә су төбендәге утырмалар уентысы күләмен 65,66 мең куб.метрга кадәр арттырырга;<br>су объектларын тергезү һәм экологик тернәкләндерү эшләре озынлыгы 20,04 километрга кадәр арттырырга;<br>су объектларын тергезү һәм экологик тернәкләндерү |

| | |
|---|---|
| | эшләре мәйданын 0,3 кв.километрга кадәр арттырырга;<br>2020 елга:<br>билгеләнгән тәртиптә бирелгән куллану хокуклары нигезендә су объектларыннан файдалануны гамәлгә ашыра торган суны кулланучылар өлешен судан файдалануны гамәлгә ашырулары су объектларыннан файдалану хокукларын сатып алуны күздә тоткан кулланучыларның гомуми санында 99 процентка кадәр арттырырга;<br>федераль милектә булган су объектларыннан файдалану өчен түләү суммаларының расланган план мәгънәләренә карата су объектларыннан файдалану өчен түләү суммаларының Россия Федерациясе бюджет системасына фактта кертелү күләме чагыштырмасын 94 проценттан ким булмаган дәрәҗәдә сакларга;<br>суны исәпләү системалары белән җиһазландырылган су алу корылмалары өлешен су алу корылмаларының гомуми санында 96 процентка кадәр арттырырга»; |

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 4 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

4 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 910 068,7 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 603 800,6 мең сум, билгеләнгән тәртиптә бирелә торган федераль бюджет акчасы – 306 268,1 мең сум.

(мең сум)

| Еллар | Акча, барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Федераль бюджет акчасы |
|---|---|---|---|
| 2014 | 599 184,9 | 508 372,8 | 90 812,1 |
| 2015 | 153 356,8 | 94 927,8 | 58 429,0 |
| 2016 | 31 905,4 | 500,0 | 31 405,4 |
| 2017 | 31 405,4 | - | 31 405,4 |
| 2018 | 31 405,4 | - | 31 405,4 |
| 2019 | 31 405,4 | - | 31 405,4 |
| 2020 | 31 405,4 | - | 31 405,4 |
| Барлыгы | 910 068,7 | 603 800,6 | 306 268,1 |

Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

4 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының биологик төрлелеген саклау» ярдәмче программасында (алга таба – 5 нче ярдәмче программа):

5 нче ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 5 нче ярдәмче программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «5 нче ярдәмче программаны финанслау күләме | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 5 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 166 223,8 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2014 елда – 24 648,6 мең сум;<br>2015 елда – 23 958,4 мең сум;<br>2016 елда – 22 689,6 мең сум;<br>2017 елда – 22 311,2 мең сум;<br>2018 елда – 23 270,5 мең сум;<br>2019 елда – 24 224,6 мең сум;<br>2020 елда – 25 120,9 мең сум.<br><br>Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»; |

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 5 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 5 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 166 223,8 мең сум тәшкил итә.

(мең сум)

| Еллар | Акча, барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|---|
| 2014 | 24 648,6 | 24 648,6 |
| 2015 | 23 958,4 | 23 958,4 |
| 2016 | 22 689,6 | 22 689,6 |
| 2017 | 22 311,2 | 22 311,2 |
| 2018 | 23 270,5 | 23 270,5 |
| 2019 | 24 224,6 | 24 224,6 |
| 2020 | 25 120,9 | 25 120,9 |
| Барлыгы | 166 223,8 | 166 223,8 |

Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

5 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының аучылык ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» ярдәмче программасында (алга таба – 6 нчы ярдәмче программа):

6 нчы ярдәмче программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 6 нчы ярдәмче программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«6 нчы ярдәмче программаны финанслау күләме</td>
<td>6 нчы ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 359 306,8 мең сум тәшкил итә, шул исәптән 235 804,4 мең сум – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, 123 502,4 мең сум – билгеләнгән тәртиптә бирелә торган федераль бюджет акчасы, шул исәптән:
<table>
<tr><th>Еллар</th><th>Акча, барлыгы</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>Федераль бюджет акчасы</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>63 899,9</td><td>45 601,8</td><td>18 298,1</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>40 072,4</td><td>25 675,6</td><td>14 396,8</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>48 324,1</td><td>30 162,6</td><td>18 161,5</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>49 741,7</td><td>31 580,2</td><td>18 161,5</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>51 099,7</td><td>32 938,2</td><td>18 161,5</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>52 450,2</td><td>34 288,7</td><td>18 161,5</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>53 718,8</td><td>35 557,3</td><td>18 161,5</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>359 306,8*</td><td>235 804,4</td><td>123 502,4</td></tr>
</table>
*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 6 нчы ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

6 нчы ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 359 306,8 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 235 804,4 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 123 502,4 мең сум.

(мең сум)

| Еллар | Акча, барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Федераль бюджет акчасы |
|---|---|---|---|
| 2014 | 63 899,9 | 45 601,8 | 18 298,1 |
| 2015 | 40 072,4 | 25 675,6 | 14 396,8 |
| 2016 | 48 324,1 | 30 162,6 | 18 161,5 |
| 2017 | 49 741,7 | 31 580,2 | 18 161,5 |
| 2018 | 51 099,7 | 32 938,2 | 18 161,5 |
| 2019 | 52 450,2 | 34 288,7 | 18 161,5 |
| 2020 | 53 718,8 | 35 557,3 | 18 161,5 |
| Барлыгы | 359 306,8* | 235 804,4 | 123 502,4 |

* Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

6 нчы ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге хезмәтләренең эшчәнлеген яраштыру» ярдәмче программасында (алга таба – 7 нче ярдәмче программа):

7 нче ярдәмче программа паспортында:

«Еллар буенча бүлеп, 7 нче ярдәмче программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «7 нче ярдәмче программаны финанслау күләме | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 7 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1 373 505,3 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2014 елда – 183 317,7 мең сум;<br>2015 елда – 232 804,6 мең сум;<br>2016 елда – 175 516,2 мең сум;<br>2017 елда – 183 765,5 мең сум;<br>2018 елда – 191 667,4 мең сум;<br>2019 елда – 199 525,7 мең сум;<br>2020 елда – 206 908,2 мең сум.<br>Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»; |

«Еллар буенча бүлеп, 7 нче ярдәмче программа максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлында:

җиденче абзацта «57,5» саннарын «60,1» саннарына алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «13,0» саннарын «11,65» саннарына алмаштырырга;

унынчы абзацта «46» саннарын «45» саннарына алмаштырырга;

унберенче абзацта «88» саннарын «95,5» саннарына алмаштырырга;

II бүлектә сиксән бишенче абзацны төшереп калдырырга;

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 7 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 7 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1 373 505,3 мең сум тәшкил итә.

(мең сум)

| Еллар | Акча, барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|---|
| 2014 | 183 317,7 | 183 317,7 |

| | | |
|---|---|---|
| 2015 | 232 804,6 | 232 804,6 |
| 2016 | 175 516,2 | 175 516,2 |
| 2017 | 183 765,5 | 183 765,5 |
| 2018 | 191 667,4 | 191 667,4 |
| 2019 | 199 525,7 | 199 525,7 |
| 2020 | 206 908,2 | 206 908,2 |
| Барлыгы | 1 373 505,3 | 1 373 505,3 |

Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

7 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

Программага әлеге карарга теркәлгән кушымта редакциясендә «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм аларны капиталь ремонтлау» ярдәмче программасын өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\383.docx